СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

15 нче декабрь, 2023 ел Алабуга шәһәре № 301

«2024 елга, 2054 һәм 2026 еллар план чорына
Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы
муниципаль берәмлеге бюджеты турында»

Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы, Алабуга муниципаль районындагы бюджет процессы турындагы Нигезләмә нигезендә, Алабуга муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1 статья

1. 2024 елга Алабуга муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга (алга таба район бюджеты);

1) район бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен
3 103 746,9 мең сум итеп;

2) район бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен
3 103 746,9 мең сум итеп;

3) район бюджеты кытлыгын 0,0 мең сум күләмендә.

2. 2025 һәм 2026 еллар план чорына Алабуга муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) район бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен - 2025 елга 3 072 176,7 мең сум итеп һәм 2026 елга 3 081 726,0 мең сум итеп;

2) район бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен - 2025 елга 3 072 176,7 мең сум итеп, шул исәптән 51 461,0 мең сум күләмендә шартлы расланган чыгымнар һәм 2026 елга 3 081 726,0 мең сум итеп, шул исәптән 103 985,2 мең сум күләмендә шартлы расланган чыгымнар;

3) 2025 елга район бюджеты кытлыгын 0,0 мең сум итеп һәм 2026 елга район бюджеты кытлыгын 0,0 мең сум күләмендә.

3. 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына район бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2 статья

1. 2025 елның 1 гыйнварына торышы буенча түбәндәгеләрне расларга:

Алабуга муниципаль районының муниципаль эчке бурычының югары чиге, шул исәптән Алабуга муниципаль районының муниципаль эчке бурычның Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләр буенча югары чиген, 0,00 мең сум күләмендә расларга;

2026 елның 1 гыйнварына торышы буенча түбәндәгеләрне расларга:

Алабуга муниципаль районының муниципаль эчке бурычының югары чиге, шул исәптән Алабуга муниципаль районының муниципаль эчке бурычның Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләр буенча югары чиген, 0,00 мең сум күләмендә расларга;

1. 2027 елның 1 гыйнварына торышы буенча түбәндәгеләрне расларга:

Алабуга муниципаль районының муниципаль эчке бурычының югары чиге, шул исәптән Алабуга муниципаль районының муниципаль эчке бурычның Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләр буенча югары чиген, 0,00 мең сум күләмендә расларга.

3 статья

2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына район бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәрен, әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә район бюджетында исәпкә алырга.

2024 елда Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетына салым түләгәннән соң калган Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының 2023 ел йомгаклары буенча башка мәҗбүри түләүләр муниципаль унитар предприятиеләре табышының бер өлеше 2024 елның 1 июленә кадәр әлеге табышның 30 проценты күләмендә башкарыла дип билгеләргә.

5 статья

1. 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына район бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын, әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2. 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль

программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне, әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә расларга.

3. 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен максатчан маддәләр (Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлүне, әлеге карарның 5 нче кушымтасы нигезендә расларга.

4. 2024 елга - 67 848,2 мең сум, 2025 елга - 69 280,9 мең сум һәм 2026 елга - 70 690,9 мең сум күләмендә ачык норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлтелгән район бюджетының гомуми бюджет ассигнованиеләрен расларга.

2024 елда район бюджетының җыелма бюджет язмасы күрсәткечләренә үзгәрешләр кертү әлеге статьяда расланган, бюджет ассигнованиеләре составында резервланган акчаларны бюджет чыгымнары классификациясе бүлекчәләре буенча бүлешүне, әлеге карарның 6 нчы кушымтасы нигезендә расларга:

1) 2024 елга 215 326,4 мең сум күләмендә;

2) 2025 елга 215 326,4 мең сум күләмендә;

3) 2026 елга 215 326,4 мең сум күләмендә.

6 статья

Район Советының район бюджеты турындагы әлеге карары нигезендә каралган товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) җитештерүчеләргә, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә һәм физик затларга субсидияләр Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә бирелә.

7 статья

2024 елга Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{10}$ статьясы нигезендә район бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара субсидияләр күләмен, әлеге карарның 7 нче кушымтасы нигезендә расларга.

8 статья

1) Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен, әлеге карарның 8 нче кушымтасы нигезендә расларга:

1) 2024 елга 102 156,7 мең сум итеп;

2) 2025 елга 43 614,7 мең сум итеп;
3) 2026 елга 23 533,2 мең сум итеп.

9 статья

Танай авыл җирлеге бюджетына гражданнар хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенция күләмен расларга:

1) 2024 елга 5,0 мең сум күләмендә;

2) 2025 елга 5,0 мең сум күләмендә;

3) 2026 елга 5,0 мең сум күләмендә.

10 статья

Муниципаль учреждениеләрне тоту буенча чыгым йөкләмәләрен үтәүгә җирлекләр бюджетыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә әлеге карарның 9 нчы кушымтасы нигезендә бүлеп бирелә торган башка бюджетара трансфертларны район бюджетында исәпкә алырга исәпкә алырга:
1) 2024 елга 457 421,2 мең сум күләмендә;
2) 2025 елга 470 664,1 мең сум күләмендә;
3) 2026 елга 470 585,8 мең сум күләмендә.

Әлеге күрсәтелгән башка бюджетара трансфертларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәү буенча чыгым йөкләмәләрен финанслауга җибәрергә.

11 статья

Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен башкару өчен муниципаль район составына керә торган җирлекләр бюджетларына субвенцияләр хисаплап чыгару һәм бирү буенча Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны

Муниципаль район составына керүче территорияләрдә хәрби комиссариатларның структур бүлекчәләре булмаган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга, җирлекләр бюджетларына субвенцияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр күләмен, әлеге карарның 10 нчы кушымтасы нигезендә расларга

1) 2024 елга 2 515,6 мең сум күләмендә;

2) 2025 елга 2 769,5 мең сум күләмендә;

3) 2026 елга 3 035,3 мең сум күләмендә.

12 статья

Алабуга муниципаль районы Юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен расларга:

1) 2024 елга 36 089,1 мең сум күләмендә;
2) 2025 елга 36 922,6 мең сум күләмендә;
3) 2026 елга 38 059,9 мең сум күләмендә.

2024, 2025 һәм 2026 елларга әлеге күрсәтелгән бюджет ассигнованиеләрен Алабуга муниципаль районының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программасы чараларын гамәлгә ашыруга җибәрергә.

13 статья

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренең, шулай ук Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль казна учреждениеләре һәм бюджет өлкәсендәге башка оешмалар хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарларны, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль казна учреждениеләренә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының башка оешмаларына яңа функцияләр яисә вәкаләтләр бирүгә бәйле рәвештә шундый карарлар кабул итү очракларыннан тыш, 2024 елда кабул итәргә хокуксыз.

2. Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнарына 2024 елда муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәүне тәкъдим итәргә.

Статья 14

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Алабуга районы буенча Казначылык департаменты территориаль бүлекчәсе төзелгән килешүләр нигезендә Алабуга муниципаль районы бюджетын үтәү буенча аерым функцияләр башкара.

15 статья

2024 елның 1 гыйнварына Алабуга муниципаль районы бюджеты акчаларының калган өлеше Алабуга муниципаль районы исеменнән товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәт күрсәтүгә муниципаль контрактлар төзелгән өчен кулланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә 2023 елда әлеге муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле муниципаль контрактлар 2024 елда Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

16 статья

Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ штрафлардан, әйләнә-тирә мохиткә, шул исәптән су объектларына китерелгән зыянны, мәҗбүри таләпләрне бозулар аркасында, каплау турындагы дәгъвалар буенча түләүләрдән, шулай ук әйләнә-тирә мохиткә, шул исәптән су объектларына китерелгән зыянны ирекле түләгәндә түләнә торган түләүләрдән салым булмаган керемнәр, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты раслый торган Алабуга муниципаль районының табигатьне саклау чаралары планы нигезендә, әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм бәяләүгә, әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыянны бетерү эшләрен оештыруга, хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын булдырмау һәм (яисә) киметү, табигать мохитен саклау һәм торгызу, табигать ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны торгызу, экологик иминлекне тәэмин итү буенча башка чараларга җибәрелә дип билгеләргә.

17 статья

Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

Рәис  Р.М. Нуриев